Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитеты Карары

2014 елның 28 мае 15№

Авыл җирлеге территориясендә Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 ст., 2011 елның 10 октябрендәге «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6.1 ст. һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясендә Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген (1 нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге территориясендә Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтле вазыйфаи затлары вәкаләтләрен расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Е.В.Краснова

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Югары Колчура
авыл җирлеге башкарма комитетының
2014 елның 28 маендагы 15 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибы

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Югары Колчура
авыл җирлеге башкарма комитетының
2014 елның 28 маендагы 15 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге территориясендә Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтле вазыйфаи затлары вәкаләтләре**

1. Муниципаль торак инспекторлары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә:

1) дәлилләнгән язма мөрәҗәгать нигезендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан сората һәм ала;

2) муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турындагы боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсен һәм хезмәт таныклыгын күрсәткәч, территорияләргә һәм аларда урнашкан күпфатирлы йортларга, күпфатирлы йортлардагы гомуми файдаланудагы биналарга, күпфатирлы йортлардагы торак биналарга тоткарлыксыз үтеп, тикшерү, шулай ук сынау, экспертиза һәм контроль буенча башка чаралар үткәрәләр.

2. Тикшерүләр уздырганда юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм граждан тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, тикшерү уздырган муниципаль торак инспекторы:

1) ачыкланган хокук бозуларны бетерү, аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яисә) кеше гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмау чараларын, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында күрсәтмәләр бирә;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерүне тикшереп тору, аларны кисәтү, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын

булдырмау чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын, шул исәптән:

а) Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына аның компетенциясе нигезендә административ хокук бозу турындагы мәсьәләне хәл итү өчен административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны җибәрә;

б) җинаять эшләрен җинаять билгеләре буенча кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрәләр.

3. Муниципаль функцияне үтәгәндә вазыйфаи затлар шулай ук: - эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары белән үзара хезмәттәшлек итәләр;

- гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә карый.